**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 2 июль № 454

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 21 август, 724 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче; 2014 ел, 31 декабрь, 1093 нче; 2016 ел, 15 февраль, 91 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

преамбулада «туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау максатларында» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында» сүзләренә алмаштырырга;

текстта «туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты

акчасы исәбеннән» сүзләрен «Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Туризм өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе»;

1 нче һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба – субсидияләр, туристлык оешмалары).

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга бәйле барлыкка килә торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында бирелә.»;

3 нче пунктта «эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 нче пунктта «капланырга тиешле» сүзләрен «финанслар белән тәэмин ителергә (капланырга) тиешле» сүзләренә алмаштырырга;

6 нчы пунктның дүртенче абзацына «турындагы нигезләмәләр» сүзләренә кадәр «Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акчаны чит ил валютасына алыштыруны тыю, югары технологияле импорт җиһазлары, чималы һәм комплект тутыру әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, шулай ук туристлык күргәзмәләрендә, презентацияләрендә, форумнарында һәм «түгәрәк өстәл» утырышларында Татарстан Республикасының катнашуын оештыру буенча оештыру кертемнәрен һәм административ эшне сатып алганда (түләгәндә), бүлмәләр, җиһаз һәм җайланмалар арендасын, дегустацияләр һәм промоакцияләр үткәрүне, презентация полиграфия һәм сувенир продукциясен эшләүне һәм таратуны, реклама хезмәтләрен кертеп, чит телләргә язма һәм телдән тәрҗемәләрне, материаллар әзерләүне, дизайнны эшләүне, чит ил дәүләтләренең туристлык оешмалары һәм массакүләм мәгълүмат вәкилләрен Татарстан Республикасы территориясендә кабул итүне кертеп, Россия визасын, медицина иминиятен рәсмиләштерүне, авиа- һәм тимер юл билетлары сатып алуны, транспорт һәм экскурсия хезмәтләре күрсәтүне, яшәү һәм туклану хезмәтләрен, мәдәни программаны оештыру, Татарстан Республикасы вәкилләренең чит илләргә баруга бәйле чыгымнарны кертеп, күрсәтелгән акчаны бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатларына ирешүгә бәйле медицина иминиятен рәсмиләштерүне, авиа- һәм

тимер юл билетлары сатып алуны, транспорт һәм экскурсия хезмәтләре күрсәтүне, яшәү һәм туклану хезмәтләрен, мәдәни программаны оештыруны кертеп, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр биргән очракта),» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 10[1] нче пункт өстәргә:

«10[1]. Субсидия бирүгә заявкаларны бәяләү критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацион, проектның (программаның, материалның) эшләнеш дәрәҗәсе;

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацион, проектның (программаның, материалның) оригинальлеге;

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацион, проектның (программаның, материалның) икътисадый һәм социаль әһәмиятлелеге нигезләмәсе;

Татарстан Республикасы территориясендә эчке һәм читтән килүчеләр туризмы өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацион, проектның (программаның, материалның) үсеш перспективалары.

Заявкалар һәр критерий буенча 5 баллык шкалада (1дән 5кә кадәр) бәяләнә.

Субсидияләр заявкалары иң күп балл җыйган гариза бирүчеләргә бирелә. Шул ук вакытта җиңүчеләр саны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән агымдагы елда субсидияләр бирүгә бүленгән бюджет ассигнованиеләре лимитларыннан чыгып билгеләнә.

Заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарлар кабул ителә:

конкурс нигезендә сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләү һәм аларга субсидияләр бирү турында;

конкурс нигезендә сайлап алуда узмаган туристлык оешмаларын билгеләү һәм аларга субсидияләр бирүдән баш тарту хакында.»;

11 нче пунктта:

икенче абзацта «һәм конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«туристлык оешмасын конкурс нигезендә сайлап алуда узмаган дип тану.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                 И.Ш.Халиков